*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ЭДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)

**10 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 45**

**1. Әдәбияттагы нинди юнәлеш турында сүз баруын язызыгыз (2 балл):**

- аның асылын Урта гасыр мөселман дөньясында киң таралган тәгълимат тәшкил итә;
- аның тарафдарларын башка төрле итеп «диндар», «дәрвиш», «тәкъва», «акыл иясе» дип йөрткәннәр;
- әдәбияттагы әлеге күренеш мөселман кешесенең үз-үзен, рухын камилләштерү юлы белән Аллага якынаюын һәм кушылуын күздә тоткан төрле системадагы дини-фәлсәфи, мистик карашлар һәм йолалар җыелмасыннан гыйбарәт.

**2. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):**

а) мәрсия, мәдхия, бәет, газәл

ә) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик озын җырлар, кыска җырлар

б) сюжетлы шигырь, поэма, баллада, нәсер

**3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.**

**а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):**

1) 2) 3)





а) ә) б)





___________________________________________

**ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):**

___________________________________________

___________________________________________

___________________________________________

**ә) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл).**

___________________________________________

___________________________________________

___________________________________________

___________________________________________

___________________________________________

___________________________________________

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

| | |
|---|---|
| 1) Мансур | а) «Әйтелмәгән васыять» |
| 2) Суфиян | ә) «Галиябану» |

3) Исмәгыйль б) «Кыйссаи Йосыф»

4) Йагъкуб в) «Ак чәчәкләр»

**5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.**

... Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык
Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;

Күтәргән кул догага, яд итә (исенә төшерә) ул шунда үз угълын:
Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!

Тамадыр мескинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)___________**

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)__________**

**б) Исегезгә төшерегез: шигырьнең беренче өлешендә нәрсә күренеше бирелә? (3 балл)____________________________________________________**

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

**в) Ана теләгенең көчен шигырьдә кайсы детальләр белдерә, шуларны язып чыгыгыз (3 балл)______________________________________________**

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

**г) Әлеге шигыре белән автор нәрсә әйтергә теләгән? Әсәрнең идеясен билгеләп языгыз (3 балл) ____________________________________________**

**6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл).**

*Кәләш, кияү, йола, туй, никах, мәҗлес, ак бөркәнчек, бал-май, хөрмәт итү, мәхәббәт хисе, бәхет теләү, әти-әни, туганнар.*

**Иншгызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы ирекле.**

**Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.**

**Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.**

.